ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш) үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1 статья. **Сирәк очрый һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар яисә үсемлекләр төрләрен юк итү**

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк очрый һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар яисә үсемлекләр төрләрен юк итүгә, шулай ук әлеге хайваннарның үлеменә, саны кимүгә йә яшәү тирәлеге бозылуга яисә мондый үсемлекләрнең юкка чыгуына китерү ихтималы булган гамәлләр (гамәл кылмау) йә күрсәтелгән хайваннарны яисә үсемлекләрне, аларның продуктларын, өлешләрен йә дериватларын шуңа тиешле рөхсәтсез яисә, рөхсәттә каралган шартларны бозып, йә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән башка тәртипне бозып, тапкан, саклаган, транспортта йөрткән, җыйган, тоткан, сатып алган, саткан йә башка урынга җибәргән өчен –

гражданнарга – ике меңнән алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – ун меңнән алып унбиш мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып ике йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 7 мае
№ 29-ТРЗ